**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 24 февраль № 109

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә мониторинг йомгаклары һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган күрсәт-кечләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү хакында» 2013 ел, 27 май, 355 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хисап елы өчен Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә мониторинг йомгаклары һәм өчьеллык чорга аларның планлаштырыла торган күрсәткечләре турында Татарстан Республикасы җыелма докладын әзерләү хакында» 2013 ел, 27 май, 355 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның өченче абзацына «территориаль органнары» сүзләреннән соң «, җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә;

3 нче пункттагы «министрлыкларына һәм ведомстволарына» сүзләрен «башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күздә тотылган, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары арасында бүленүче күрсәткечләрнең Татарстан Республикасы җыелма докладына кертелә торган исемлегендә:

исеменә «территориаль органнары» сүзләреннән соң «, җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә;

4 нче пункттагы 3 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча)»;

29 нчы пункттагы 3 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\109.doc